Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Байлангар авыл җирлеге Башлыгы

карары

28 октябрь, 2025 ел №4

«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 14 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Сазтамак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыен Сазтамак авылы Ленин урамында спорт мәйданчыгы янында уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәгеләрдән тыш:

- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган аналар;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзалары» –

1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, коймалар кору, ремонтлау;

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен

тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү

«РИЗА» - ?  «КАРШЫ» - ?

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

6. Байлангар авылы Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы:  И.Ф. Кәримуллин

ОГРН 1021607752814
ИНН 1623001621